# КАРАР

**24 ноябрь, 2021 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Югары Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча 2021 елның 24 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының нәтиҗәсе буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, балачактан инвалид балалар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Югары Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- бакча һәм Көнчыгыш урамнарында юл полотносын тигезләү (ремонт), Мәктәп урамында «ятып торучы полицейский»урнаштыру(резин).
- Югары Комар авылында тышкы камералар белән видеокүзәтү сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Югары Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту ( юлларны кардан чистарту һәм җәйге чорда грейдлау; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);;
- тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 247 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 140 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 140 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Югары Комар авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, балачактан инвалид балалар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Югары Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- бакча һәм Көнчыгыш урамнарында юл полотносын тигезләү (ремонт), Мәктәп урамында «ятып торучы полицейский»урнаштыру(резин).

- Югары Комар авылында тышкы камералар белән видеокүзәтү сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);

- Югары Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту ( юлларны кардан чистарту һәм җәйге чорда грейдлау; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);;

- тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);

- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Комар
авыл җирлеге башлыгы Ю.И.Исынбаев